**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Чалпинского сельского поселения**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай**
**муниципаль районы Чалпы авыл жирлеге**
**Советы**
**БАШЛЫГЫ**

**ул. Центральная, д.35, с. Чалпы, 423324**
**Азнакаевского муниципального района**
**Тел. (8-5592) 35-5-46, факс (8-5592) 35-5-46**
**Chal.Azn@tatar.ru**

**Узэк урамы, 35, Чалпы авылы, 423324**
**Тел. (8-5592) 35-5-46,**
**факс (8-5592) 35-5-46**
**Chal.Azn@tatar.ru**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» ноябрь 2019 ел № 5

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлегенең Чалпы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Чалпы авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 12 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә: Гагарин урамы 1 йорттан 33йотка кадәр, Казан урамы 1йорттан 62 йортка кадәр, Ленин урамы 1йорттан 131 йортка кадәр.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Чалпы авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 12 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә: Ленин урамы 132 йорттан 190 йотка кадәр, Яшьләр урамы 1йорттан 22 йортка кадәр, Яңа урамы 1йорттан 5 йортка кадәр, Бакчалы урамы 1 йорттан 104 йортка кадәр, Үзәк урамы 1йорттан 29 йортка кадәр.

3.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Чалпы авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының беренче этабын уздыру вакыты – 12 ноябрь 2019 ел 10.00 сәг.тән 11.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты – 12 ноябрь 2019 ел 13.00 сәг.тән 14.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын уздыру урыны – Чалпы авылы, Үзәк ур. , 24 йорт, Чалпы авыл мәдәният йорты залы;

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 6 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла

торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Чалпы авылы, Үзәк урамы, 35 йорт

- сайлау хокукына ия булган Чалпы торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;
- Чалпы торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 Чалпы авыл җирлеге Чалпы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Чалпы авылында Ленин урамына, Яшьләр урамына, Бакчалы урамына, Яңа урамына, Гагарин урамына, Казан урамына, вак таш җәелгән юлларның чокырларын ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Чалпы авылында урам утларын, яктырткычларны, махсус җиһазларны сатып алу, энергия саклаучы лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Чалпы авылы территориясендә көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны вакытлыча җыю территорияләрен җыештыру, чистарту;
- Чалпы авылы зиратлары өчен җиһазлар һәм инвентарь сатып алу;

Чалпы авылында янгын сүндергечләр, янгын сундерү ранецлары, янгын инвентаре сатып алу;

- Чалпы юлларын кардан чистарту;
- Чалпы авылының җәйге чорында территорияне чабу;
- Чалпы авылында коры агач, куак кисү;
- Чалпы авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү) ;
- Чалпы авылында һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлләрне ремонтлау (киртә урнаштыру, буяу, агарту, килешү буенча эш өчен түләү);
- Чалпы авылында Һәйкәл (мемориаль такталар) урнаштыру;
- Чалпы авылында урам исемнәре язылган табличкалар ясау;
- Чалпы авылындагы гидротехник корылма янында «су коеныrга ярамый» дигән табличкалар ясау, урнаштыру;
- Чалпы авылында («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү.

« РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Чалпы авылы, Ленина ур., 130 йорт, Үзәк ур., 39 йорт, Чалпы авылы мәктәп бинасында, амбулатория бинасында урнашкан мәгълүмат стендларында, Камышлы, Ирекле, Балан-Бүләк авыллары мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: А.М. Мөхәмәтшин